РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

**РЕШЕНИЕ** **№ 60** **КАРАР**

25 ноябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2023 нче елга һәм 2024-2025 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2023 нче елга һәм 2024-2025 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» гы мәгълүматны тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2023 нче елга һәм 2024-2025 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2023 нче елга һәм 2024-2025 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы Рәисе Н.Н. Хуҗина

Кушымта 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенен
2023 нче елга һәм 2024-2025 нче елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Хисап | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 470 | 460 | 455 | 450 | 450 | 450 |
| Темп роста к предыдущему году | % | -1,67 | -2,12 | -1,08 | -1,09 | 0 | 0 |
| Эре мөгезле терлекләр саны | Баш саны | 339 | 358 | 363 | 365 | 366 | 370 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,2 | 2,6 | 1,4 | 0,55 | 0,27 | 1,09 |
| Инвестицияләр | мең сум | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Торак төзелеше | кв.м. | 0 | 0 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 0 | 100 | 0 | 0 | 0 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 7565,2 | 7860,2 | 8528,3 | 9157,9 | 9427,5 | 10191,1 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | -7 | +3,9 | +8,5 | +7,4 | +2,9 | +8,1 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 35024,1 | 36389,8 | 39482,9 | 42397,7 | 46213,2 | 47181 |
| Эшчеләр саны | кеше | 18 | 18 | 18 | 18 | 17 | 18 |
| Эшкуарлар саны (КФХ) | кеше | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| Эшсезләр саны | кеше | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 |

Шәрләрәмә авыл җирлеге баш белгече Хәлиуллина С. А.

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024-2025 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.
2023-2025 нче елларга Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2023-2025 нче елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең 2022 елның көтелгән нәтиҗәләрен һәм 2023-2025 елларда икътисад һәм социаль өлкәне үстерү тенденцияләрен, 2023-2025 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып, барлыкка килгән социаль - икътисадый үсеш торышын анализлап чыгару максатында, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә анализ ясалды.
2023-2025 елларда «Urals» нефтькә бәяләр баррель өчен 71,4-61,2 АКШ доллары дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана.
2023 елда доллар курсы уртача еллык АКШ доллары өчен 77 сум, 2024 елда – 78,7 сум булыр дип фаразлана. 2025елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 81 сум тәшкил итәчәк.
Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә, Кормаш, Сөлек авылларыннан тора.
2023 елга Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә халык саны – 450 кеше, 2024 елга – 450, 2025 елга 450 кеше тәшкил итәчәк.
Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Агрокөч төркеме» ЯАҖнең «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖенең, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның потенциалын һәм бүгенге үсеш тенденцияләрен, шулай ук «агросәнәгать комплексын үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.
Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖ «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ һәм "Таипов" КФХ эшчәнлеге алып бара.
2023-2025 елларда 300 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.
2022 елда хезмәт хакы фонды 8,5 миллион сум тәшкил итәчәк.
2023 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 9,1 сум, 2024 елда – 9,4 миллион сум, 2025елда 10,2 миллион сум тәшкил итәчәк.
Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны 18 кеше тәшкил итә.
2022елда уртача хезмәт хакы 39482,9сум тәшкил итәчәк. 2023 елга фараз буенча ул 42397,7 сум, 2024 елда – 46213,2 сум, 2025 елда 47181,0сум тәшкил итәчәк.
2023 елга эшмәкәрләр саны 12 кеше тәшкил итәчәк, 2024 елга-12, 2025 елга-12 кеше.